**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Морза Бәрлебаш торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**28 ноябрь, 2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 27 нче ноябрендә 14 сәгатьтә, 2025 елның 28 нче ноябрендә 15 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авылҗирлеге Морза Бәрлебаш авылыда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау ( шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер, СИП чыбыклары сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (шул исәптән янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгы тирәсен чабу,трактор тоту).
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 88 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 52 кеше, бу 59,09 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 52 катнашучы тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең Морза Бәрлебаш торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

2.«Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Морза Бәрлебаш авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (бишйөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен урнаштыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау ( шул исәптән светодиодлы урам яктырткычлары, таймер, СИП чыбыклары сатып алу);
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (шул исәптән янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (шул исәптән территорияне, балалар мәйданчыгы тирәсен чабу,трактор тоту).
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә» – кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гыйзәтуллина